| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**26.01.2022** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 127** |
|---|---|---|

Аерым муниципаль хокукый актларның үз көчләрен югалтуын тану турында

Россия Федерациясе Граждан кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск шәһәре Советының «Зеленодольск шәһәре территориясендә муниципаль контроль турында нигезләмәләрне раслау хакында» 2021 елның 17 декабрендәге 68 номерлы карарын, Зеленодольск муниципаль районы Советының «Зеленодольск муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 19 декабрендәге 102 номерлы карарын кабул итү белән бәйле, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының норматив-хокукый актлары системасын актуальләштерү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарларының үз көчләрен югалтуын таныргa:

- «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләр – авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 2017 елның 18 сентябрендәге 2390 номерлы;
- 2018 елның 30 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләр – авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 2017 елның 18 сентябрендәге 2390 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 1529 номерлы карары;
- 2020 елның 23 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 18 сентябрендәге 2390 номерлы карары белән расланган «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләр – авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруның административ регламентына үзгәрешләр кертү турында »гы 1335 номерлы карары.

2. Зеленодольск муниципаль район Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә буенча бүлек начальнигына әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составындагы Зеленодольск муниципаль районы рәсми порталында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев